**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82,e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
**16 июнь 2023 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 72**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясенен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 1 маддәсенең 3 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2020 елның 15июнендәге 167 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельское авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (2021 нче елның 2 нче сентябрендәге 29 нче номерлы Совет карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә :

1) 66, 67, 68 нче пунктларда «тимер юл» сүзен чыгарырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау тимер юл станция поселогы, Совет урамы, 13 йорт адресы буеннча,Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында урнашкан мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Нуруллинга йөкләргә.

Красносельский авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары Р.Р. Никитенко